| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>НУРЛАТСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ** |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Киекле ав. | **КАРАР** |
| «05» ноябрь 2024 ел | | № 5 |

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. 2024 елның 20 ноябрендә 08 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Заречная урамы, 14 адресы буенча урнашкан торак йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Заречная, Родниковая, Космонавтлар урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.
2. 2024 елның 20 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Сәүдә урамы, 19 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Торговая, Молодежная, Олимпийская, Рабочая урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.
3. 2024 елның 20 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Совет урамы, 44 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Советская, Садовая, Солнечная, Школьная урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.
4. 2024 елның 20 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Комсомол урамы, 6 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Комсомольская, З. Каримова, Колхозная, Луговая урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.
5. 2024 елның 20 апрелендә 17 сәгать 00 минутка Киекле авылы, Заозерная урамы, 5 адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылында Заозерная, Сибирская, Нижняя урамында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыруны билгеләргә.
6. Гражданнар җыенын уздыру өчен Киекле авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

7. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

8. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда Киекле авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылар тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- эчәр су белән тәэмин итү һәм суны агызып җибәрү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, лицензияләү, төзү һәм ремонтлау;

- Киекле торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, шул исәптән таш, ваклаган кирпеч, грунт, вак таш, ком, асфальт ватыклары салу (сатып алу, ташу, салу), чокырларны ремонтлау (коелган асфальт);

- урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтү өчен түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күпләп ял итә торган урыннары (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннары) товарларын (эшләрен, хезмәт күрсәтүләрен) сатып алу һәм аларга якын территорияне төзекләндерү);

- Киекле торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү;

- Киекле торак пунктында өч традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, коймаларны төзү, ремонтлау.

«РИЗА» «КАРШЫ»

9. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авылының мәгълүмат стендларында халык җыены үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

10. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы Л.И. Кашапова